МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.10.2016 г. Казань № 916 од

«Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2014 елның 20 гыйнварындагы 22 од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп

БОЕРАМ:

1. «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2014 елның 20 гыйнварындагы 22 од номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2014 ел, 19 июнь, 679 од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкка 2 нче кушымтага:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданин (граждан хезмәткәре) вакантлы граждан хезмәте вазыйфасының квалификацион таләпләренә туры килмәсә, шулай ук дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән граждан хезмәтенә керү һәм аны үтү буенча чикләүләр булса, конкурска кертелми.»;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Һөнәри белем, дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек буенча эш дәрәҗәсенә квалификацион таләпләр:

граждан хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә караган «җитәкчеләр» категориясенә специалитет, магистратура дәрәҗәсеннән дә түбән булмаган югары белем, граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы яки өлкән төркемендә ике елдан да ким булмаган яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча өч елдан да ким булмаган эш стажы булуы мәҗбүри;

граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменә караган «җитәкчеләр» категориясенә югары белем, граждан хезмәте вазыйфаларының өлкән яки кече төркемнәрендә бер елдан да ким булмаган граждан хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы булуы мәҗбүри;

дәүләт хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменә караган «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясенә югары белем, бер елдан да ким булмаган дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы булуы мәҗбүри;

граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменә караган «белгечләр» категориясенә югары белем, бер елдан да ким булмаган дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы булуы мәҗбүри;

граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменә караган «тәэмин итүче белгечләр» категориясенә югары белем, граждан хезмәте вазыйфаларының өлкән яки кече төркемнәрендә бер елдан да ким булмаган граждан хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы булуы мәҗбүри;

граждан хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркеменә караган «тәэмин итүче белгечләр» категориясенә эшчәнлек юнәлешенә туры килгән һөнәри белем мәҗбүри. Граждан хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркеменә караган граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен граждан хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына (тәҗрибәгә) квалификацион таләпләр куелмаган.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле белем һәм сәләткә карата квалификацион таләпләр дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламентындагы профессиональ эшчәнлеге өлкәсеннән һәм төреннән чыгып билгеләнә.

Дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен зарур булган белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә квалификацион таләпләр дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламенты буларак та карала ала.»;

боерыкка 3 нче кушымтада:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданины Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза (әлеге Исемлеккә 1 нче кушымта);

б) 4x6 үлчәмдәге 2 фотосурәт теркәлгән, үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета (әлеге Исемлеккә 2 нче кушымта);

в) паспорт яисә аны алыштыручы документ күчермәсе (туры килә торган конкурска килгәч күрсәтелә);

г) тиешле һөнәри белемен, квалификациясен һәм эш стажын раслаган документлар:

нотариаль юл белән яисә эш (хезмәт) урынының кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт итү эшчәнлеге беренче тапкыр гамәлгә ашырылу очраклары искәрмә булып тора), яисә гражданинның хезмәт итү эшчәнлеген дәлилли торган теләсә нинди документлар;

белем турында һәм квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданин теләге белән нотариаль юл белән яки эш (хезмәт) урынындагы кадрлар хезмәтендә расланган гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документларның, өстәмә һөнәри белем алу һәм аның нәтиҗәләре буенча квалификация бирелүне раслаган документларның күчермәләре;

д) гражданинда граждан хезмәтенә керергә яисә аны үтәргә тоткарлык тудыра торган чирләр булмавы турында документ;

е) «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 ел, 27 июль, 79-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты Указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында, «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 ел, 16 гыйнвар, 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган башка документлар.».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М.Сибагатуллин